КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 22 сентябрь г.Казань № 726

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча бер белем алучының кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар;

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына башлангыч гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча бер укучыга кайнар ризыкның уртача бәясе.

2. Җирле үзидарә органнарына 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү буенча шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф

программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында» 2024 ел, 12 сентябрь, 777 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында» 2024 ел, 12 сентябрь, 777 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 ел, 21 апрель, 253 нче.

4. Бу карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 22 сентябрь, 726 нчы карары белән расланды

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар

| Норматив чыгымнар исеме | Бер көнгә бер белем алучыга норматив чыгымнар күләме, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар | 77,76 | 80,87 | 84,1 |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 22 сентябрь, 726 нчы карары белән расланды

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына башлангыч гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча бер укучыга кайнар ризыкның уртача бәясе

| Күрсәткеч исеме | Бер көнгә бер белем алучыга күрсәткеч зурлыгы, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| Башлангыч гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча бер укучыга кайнар ризыкның уртача бәясе | 77,76 | 80,87 | 84,1 |

________________________